ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**18.11.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2925**

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә кешеләр күпләп җыела торган урыннар исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыру өчен билгеләнгән объектларның (территорияләрнең) террорчылыктан сакланышына карата таләпләрне һәм балаларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыру өчен билгеләнгән стационар типтагы объектларның (территорияләрнең) куркынычсызлык паспортының формалары» 2021 елның 14 маендагы 732 номерлы карарына таянып, шулай ук ««Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле кешеләр һәм объектлар (территорияләр) күпләп җыела торган урыннарның террорчылыкка каршы саклануына таләпләрне һәм мондый урыннарның һәм объектларның (территорияләрнең) иминлек паспортлары формаларын раслау турында»» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 25 мартындагы 272 номерлы карары таләпләрен үтәү йөзеннән, Зеленодольского муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә кешеләр күпләп җыела торган урыннар исемлеген (алга таба Исемлек) Кушымтада каралганча расларга.
2. Исемлектә күрсәтелгән, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, предприятие, учреждение, оешма һәм объект (территория) җитәкчеләренә (хокукка ия булучыларга) кешеләр күпләп җыела торган урыннарның террорчылыкка каршы сакланышын тәэмин итү өлкәсендә эшләр башкаруны тәэмин итәргә;
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы территориясендә кешеләр күпләп җыела торган урыннар исемлеген раслау турында» 2020 елның 10 гыйнварындагы 09 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. ЗМР Аппараты Советының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин

**Килештерелде**
ТР буенча РФ ФИХИ (УФСБ РФ по РТ)
Зеленодольск шәһәрендәге бүлек башлыгы
__________________ Д.Л. Антонов
"_____"______________ 2021 ел

**Килештерелде**
«Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләренең ведомстводан тыш саклау идарәсе» ФДКУ ТР буенча филиалы - Зеленодольск районы буенча ведомстводан тыш сак бүлеге башлыгы

___________________ Г.Г. Минуллин
"_____"______________ 2021 ел

**Килештерелде**
ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең
Зеленодольск муниципаль районы буенча
күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге башлыгы
__________________ Р.Р. Ардыханов
"_____"______________ 2021 ел

**Килештерелде**
Зеленодольск районы буенча
Россия Эчке эшләр министрлыгының бүлек башлыгы

___________________А.Р. Ханбиков
"_____"______________ 2021 ел

**Категорияләре буенча**
**Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан**
**кешеләр күпләп җыела торган объектларның**
**исемлеге**

| № т/б | Объект исеме | Юридик адресы, телефоны | Эшчәнлек өлкәсе |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| **Кешеләрнең 2 категорияле массакүләм булу урыннары (бер үк вакытта 200 дән 1 000 гә кадәр)** | | | |
| **Сәламәтләндерү-дәвалау учреждениеләре** | | | |
| 1 | «Серго исемендәге завод» ҖБ» АҖ «Волга» шифаханә-профилакториясе | Зеленодольск шәһәре<br>Гагарин ур.,1 нче йорт; 5-76-47 | шифаханә-профилакторий |
| 2 | «А.М. Горький исемендәге Зеленодольск заводы» АҖ<br>"Дельфин» шифаханә-профилакториясе | Зеленодольск шәһәре<br>Загородная, ур. 5нче йорт; 5-81-57 | шифаханә-профилакторий |
| 3 | «Васильевский» ЛПУС | ЗМР, Васильево штп<br>8 (843) 204-11-53, 6 22-21 | шифаханә-профилакторий |
| 4 | Шифаханә «Сосновый бор» ҖЧҖ | ЗМР, Васильево штп, А. Чуркин ис. тык.,1нче йорт, 8 (843) 211-79-51, 6 30-05 | шифаханә-профилакторий |
| **Кешеләрнең 3 категорияле массакүләм булу урыннары (бер үк вакытта 50 дән 200 гә кадәр)** | | | |
| **Күмү (зират) территориясе** | | | |
| 1 | «Шәһәрнең» җирләү урыны | Зеленодольск шәһәре | зират |
| 2 | «Гариның» җирләү урыны | Зеленодольск шәһәре | зират |

**КЕШЕЛӘРНЕҢ МАССАКҮЛӘМ БУЛУ УРЫННАРЫ ҖЫЕЛМА ИСЕМЛЕГЕ**

| **№** | **Кешеләр күпләп була торган объектлар** | **Барлыгы** | **Категория буенча** | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Шифаханә -профилакторийлар | 4 | I | II | III |
| 2 | Зиратлар | 2 | **0** | **4** | **2** |
| | **Барлыгы:** | **6** | | | |